# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«08» 05 2024 № 1147

«Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 1473 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н. Миңнехановның 2024 елның 1 июленнән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакын арттыру турында карары һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2024 елның 18 апрелендәге 03-12/2677 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Тукай муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 1473 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган «Тукай муниципаль районының бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәдә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Тукай муниципаль районының бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Җитәкче | 31 700 |
| Җитәкче урынбасары | 29 500 |
| Бүлек башлыгы | 25 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 23 300 |
| Бухгалтер | 22 000 |

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. «Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хабибуллин